СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«16» апрель 2024 ел** **№ 276**

**«Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә классны чиннар бирү һәм аттестация үткәрү тәртибе турында» Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 331 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (10.11.2015 №17, 10.11.2016 №81, 14.03.2020 № 237, 19.09.2019 № 270, 20.05.2020 №329, 16.10.2020 №19, 20.04.2021 №58 үзгәрешләр белән)**

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү, классны чиннар бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, эш стажын билгеләү өчен муниципаль хезмәттә эшләгән елларны исәпләү буенча комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1.«Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә классны чиннар бирү һәм аттестация үткәрү тәртибе турында» Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 331 номерлы карары (10.11.2015 №17, 10.11.2016 №81, 14.03.2020 № 237, 19.09.2019 № 270, 20.05.2020 №329, 16.10.2020 №19, 20.04.2021 №58 үзгәрешләр белән) белән расланган муниципаль хезмәткәргә классны чиннар бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, эш стажын билгеләү өчен муниципаль хезмәттә эшләгән елларны исәпләү буенча комиссия составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

-Комиссия составыннан Э.И.Салихованы чыгарырга;

-Комиссия составына Комиссия секретаре сыйфатында Ч.Р. Вильданованы-Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдирен кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары А.Ф.Мөхәмәтовага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
16 апрель 2024 ел, № 276
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү, классыл чиннар бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, эш стажын билгеләү өчен муниципаль хезмәттә эшләгән елларны исәпләү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Салихова Эльвина Илфатовна | - Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире, комиссия секретаре. |

***Комиссия әгъзалары***

| | |
|---|---|
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советы аппаратының оештыру-гомуми бүлеге башлыгы; |
| Галимова Светлана Петровна | - "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы" МКУ җитәкчесе; |
| Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы; |
| Сафиуллин Айдар Габделфәртович | - Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятенең информатика һәм математика укытучысы, ИКТ буенча директор урынбасары, (килешү буенча). |

шулай ук килешү буенча муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү, классыл чиннар бирү өчен квалификация имтиханнары кабул итү, эш стажын билгеләү өчен муниципаль хезмәттә эшләгән елларны исәпләү үткәрелә торган Арча муниципаль районы үзидарә органы җитәкчеләре (җирлек башлыклары).